**Рус мәктәпләрендә татар әдәбиятыннан төп гомуми белем мәктәп курсы өчен үрнәк билетлар**

**Примерные билеты по татарской литературе за курс основной школы для русских школ**

## Аңлатма язуы

2011-2012 нче уку елында IX сыйныфны тәмамлаучыларга шул сыйныфка мөнәсәбәтле һәм укучы үзе сайлап алган теләсә кайсы фәннән телдән имтихан тапшыру рөхсәт ителә. Укучылар тарафыннан сайланган имтиханнар яңа һәм традицион формада уздырыла.

Татар әдәбиятыннан телдән имтиханны төрле формаларда оештырырга мөмкин (**әңгәмә, реферат яклау, билетлар нигезендә имтихан тапшыру**).

**Әңгәмә** билгеле бер темага нигезләнеп (ул тема укучыга алдан ук билгеле була), әзерлексез төстә генә укучының киңәйтелгән җавабын тыңлау формасында оештырыла. Мондый форманы татар әдәбияты фәнен яхшы белгән укучыларга тәкъдим итү уңышлы, чөнки ул укучы һәм имтихан алучы укытучының үзара әңгәмәсенә корыла, ә укытучы моңа кадәр үтелгән әдәбият курсына мөнәсәбәтле теләсә нинди сорау аша укучының белем дәрәҗәсен ачыклый ала.

Имтиханны **реферат яклау** формасында тапшыру мөстәкыйль фикер йөртергә һәм язма эш башкарырга сәләтле укучылар өчен отышлы. Уку елының икенче яртысы башлануга укучы укытучысы белән билгеле бер теманы сайлап ала һәм аңа кагылышлы тәнкыйди, фәнни-методик, әдәби материалны туплый. Рефератта өйрәнү объекты, аның асылы төгәл билгеләнергә, төп нәтиҗәләр чыгарылырга, әдәбият исемлеге тәкъдим ителергә тиеш. Бу очракта имтиханга бер атна кала танышып һәм бәяләп чыгу өчен реферат укытучыга тапшырыла. Имтихан вакытында комиссия рецензия белән таныша һәм укучы тарафыннан хезмәт якланганнан соң билге куела.

Имтиханны **билетлар** ярдәмендә тапшыру иң отышлы һәм киң таралган форма буларак билгеле. Рус мәктәпләрендә татар әдәбиятыннан имтиханны традицион формада уздыру өчен үрнәк билетлар “Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең вакытлы дәүләт стандарты”на (Казан, 2008), “Урта гомуми белем бирүче мәктәпләр өчен татар теле һәм әдәбиятыннан программа”га (5-11 нче сыйныфлар) (К:. Мәгариф, 2010), нигезләнеп төзелде.

Имтихан билетлары, нигездә, 7, 8, 9 нчы сыйныф материалларына таянып төзелде, аерым очракларда алдагы сыйныфта үтелгәннәргә дә мөрәҗәгать ителде. Шул критерийлар нигезендә сораулыклар төзүнең билгеле бер системасы эшләнде. Имтихан билетларында беренче сораулар аерым бер әдип иҗаты хакында мәгълүмат бирүне һәм аның күрсәтелгән әсәрен бәяләүне алга куя, әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып

алуны, әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгели алуны таләп итә.

Икенче сорау тәкъдим ителгән әсәргә билгеләнгән яссылыкта анализ ясауга йөз тота һәм укучының теге яки бу әсәр сюжетына кагылышлы элементларны билгели алуын, геройга характеристика бирү мөмкинлеген тикшерү максатын алга куя. Моннан тыш сораулар укучының әдәбиятны, әсәрне аңлау дәрәҗәсен генә түгел, аңа шәхси мөнәсәбәтен белдерү, логик фикерләү дәрәҗәсен, иҗади мөмкинлекләрен, эрудициясен дә ачыкларга мөмкинлек бирә.

Имтихан өчен **2 комплект билетлар** тәкъдим ителә: аларның берсе татар мәктәпләрендә укучы татар балаларына, икенчесе рус мәктәбендә белем алучы татар укучыларына йөз тотып төзелде.

Әлеге ике комплект имтихан билетлары да үрнәк буларак тәкъдим ителә һәм мәктәпләр тарафыннан имтихан билетлары төзү барышында кулланыла ала. Укытучы аларны үзгәртү хокукына ия: сорауларның урыннарын, формулировкаларын алыштырырга яки аерым сорауларны үзгәртергә мөмкин.

Имтихан барышында укчыга **әзерлек өчен 40 минут** вакыт бирү күздә тотыла.

## Укучының җавабын билгеләүгә күрсәтмәләр

Имтиханда укучының җавабын билгеләү барышында түбәндәге критерийлар исәпкә алынырга тиеш:

- укучының сорауны аңлап, төгәл җавап бирүе;
- әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы куллануы;
- җавабын мисаллар ярдәмендә ныгытуы, соралган әсәрне (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдалануы (цитататалар китерү, әсәрләргә сылтамалар бирү һ.б.);
- җавапның нигезле, дәлилләнгән булуы;
- җавапның логик яктан эзлекле булуы, укучының үз фикерләрен үзара бәйләнештә бирүе, төгәл җиткерә алуы;
- өзекләрне сәнгатьле сөйли алуы;
- җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе.

Әгәр укучы билет сорауларына дөрес, төгәл җавап биргән һәм җавап алдагы критерийларга туры килгән очракта **«5»ле билгесе** куела.

Әгәр укучы билетның ике соравына бик яхшы җавап биреп, өченчесенә төгәл җавап булмаган яки сорауларның өчесенә җавап биреп тә, алда күрсәтелгән теге яки бу критерий үтәлмәгән очракта **«4»ле билгесе** куела.

Әгәр укучы билетның бер соравына җавап биреп, икесенә төгәл җавап булмаган яки сорауларның өчесенә өстән-өстән җавап биреп тә, алда күрсәтелгән төп таләпләр үтәлмәгән очракта **«3»ле билгесе** куела.

## Татар әдәбиятыннан имтихан билетларын төзү өчен кирәкле әдәбият исемлеге

(үрнәк)

**Халык авыз иҗаты**

“Сак-Сок бәете”
Сөембикә бәете

**XX гасыр татар әдәбиятыннан**

Габдулла Тукай. “Исемдә калганнар”, “Туган авыл” һ.б.
Гаяз Исхакый. “Сөннәтче бабай”, “Җан Баевич”.
Галимҗан Ибраһимов. “Алмачуар”.
Галиәсгар Камал. “Беренче театр”.
Шәриф Камал. “Буранда”.
Һади Такташ. “Мокамай”.
Муса Җәлил. “Бакчачы”, “Имән”, “Катыйльгә” һ.б.
Гадел Кутуй. “Сагыну”, “ Рөстәм маҗаралары”.
Мирсәй Әмир. “Агыйдел”.
Хәсән Туфан. “Кайсыгызның кулы җылы?”, “Киек казлар”, “Кемнәр сез?” һ.б.
Сибгат Хәким. “Әй, язмыш, язмыш”, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә”, “Кырыгынчы бүлмә”.
Нәби Дәүли. “Яшәү белән үлем арасында”.
Габдрахман Әпсәләмов. “Ак чәчәкләр”.
Ибраһим Гази. “Ак сирень”, “Кояш артыннан киткән тургай”.
Әмирхан Еники. “Кем җырлады?”.
Гомәр Бәширов. “Туган ягым – яшел бишек”.
Аяз Гыйләҗев. “Җомга көн, кич белән”.
Гариф Ахунов. “Идел кызы”.
Илдар Юзеев. “Таныш моңнар”, “Гашыйклар тавы”.
Фәнис Яруллин. “Җилкәннәр җилдә сынала”, “Ана”.
Миргазиян Юныс. “Шәмдәлләрдә генә утлар яна”.
Мәдинә Маликова. “Чәчкә балы”.
Ринат Мөхәммәдиев. “Беренче умырзая”.

## Билет №1

1. Матур әдәбият, аның төп үзенчәлекләре. Матур әдәбиятның кеше тормышындагы роле.
2. Г.Тукайның “Туган авыл” шигырендә лирик геройга характеристика бирегез.

## Билет №2

1. Гомәр Бәширов иҗаты, аның “Туган ягым – яшел бишек” әсәре, вакыйгалар. Гомәр образы.
2. Хәсән Туфанның “Кайсыгызның кулы җылы?” шигырендә лирик геройның хәсрәте хакында сөйләгез.

## Билет №3

1. Габдрахман Әпсәләмов иҗаты, үзенчәлекләре, аның иң яхшы әсәрләреннән буларак “Ак чәчәкләр” романы.
2. Гадел Кутуйның “Сагыну” нәсерендә туган илне сагыну хисенең бирелеше.

## Билет №4

1. Татар халкының милли йола һәм бәйрәмнәре.
2. Муса Җәлилнең “Имән” шигыренә анализ ясагыз.

## Билет №5

1. Илдар Юзеев иҗаты, аның әсәрләрендә мәхәббәт темасының чагылышы (“Таныш моңнар”, “Гашыйклар тавы”).
2. Галимҗан Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясенең сюжеты, Закир образына бәя бирегез.

## Билет №6

1. Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты хакында мәгълүмат бирегез.
2. Галиәсгар Камалның “Беренче театр” комедиясендә конфликт үзенчәлеге.

## Билет №7

1. Гаяз Исхакый иҗаты хакында мәгълүмат бирегез, “Җан Баевич” әсәренең үзенчәлеге.
2. Габдулла Тукайның “Исемдә калганнар” автобиографик әсәрендә авторның үз-үзенә бәясе.

## Билет №8

1. Шәриф Камалның “Буранда” әсәрендә образлар системасына бәя бирегез. Буран образына салынган мәгънәләрне ачыклап карагыз.
2. Сибгат Хәким шигырьләрендә туган як темасы. (“Әй, язмыш, язмыш”, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә ( укучы

үзе сайлый).

## Билет №9

1. Г.Камал иҗаты, татар драматургиясе һәм театрның формалашуына, үсешенә керткән өлеше хакында мәгълүмат бирегез.
2. Сибгат Хәкимнең “Кырыгынчы бүлмә” поэмасында Тукай образы.

## Билет №10

1. М.Әмирнең “Агыйдел”, Һ.Такташның үзегез теләгән бер әсәре мисалында пейзажның вазифаларын (функциясен) билгеләгез. Табигать күренешләре ни өчен кертелгән дип уйлыйсыз?
2. Гаяз Исхакыйның “Сөннәтче бабай” повестенда Сөннәтче бабай кичерешләренә бәя бирегез.

## Билет №11

1. Нәби Дәүлинең тормыш юлы, иҗаты хакында мәгълүмат бирегез. “Яшәү белән үлем арасында” романында сугыш темасының яңача сурәтләнеше.
2. Муса Җәлилнең “Катыйльгә” шигырендә лирик герой хәсрәте.

## Билет №12

1. Хәсән Туфанның тормыш юлы һәм иҗаты.
2. Ибраһим Газиның “Ак сирень” хикәясендә мәхәббәт темасы.

## Билет №13

1. Әдәби әсәрдә тема, проблема, идея (мисаллар китереп аңлатырга). Портрет һәм пейзаж.
2. Хәсән Туфанның “Киек казлар” шигыренә анализ ясагыз.

## Билет №14

1. Тел-сурәтләү чаралары: эпитет, метафора, чагыштыру, сынландыру, аллитерация һ.б. (мисаллар өстендә аңлатырга).
2. Ибраһим Газиның “Кояш артыннан киткән тургай” хикәясендә тургай образына бәя бирегез.

## Билет №15

1. Әмирхан Еникинең “Кем җырлады?” хикәясе мисалында сугыш темасының чагылышын аңлатыгыз.

2. Һади Такташның “Мокамай” әсәрендә лирик геройның кичерешләре хакында сөйләгез.

## Билет №16

1. Г.Ахунов иҗаты хакында мәгълүмат бирегез, “Идел кызы” романы.
2. Мәдинә Маликованың “Чәчкә балы” повестенда чәчкә балы образының мәгънәсен әсәр сюжеты белән бәйләнештә аңлатыгыз.

## Билет №17

1. Баллада жанры, аның төп үзенчәлекләре (Фәнис Яруллинның “Ана” балладасы мисалында).
2. Гадел Кутуйның “Рөстәм маҗаралары” әсәрендә Рөстәм образына бәя бирегез.

## Билет №18

1. Татар халык авыз иҗаты, төп жанрлары. Җырларга, табышмакларга, хас сыйфатлар.
2. Ринат Мөхәммәдиевның “Беренче умырзая” повестенда табигать образлары, аларга салынган мәгънә.

## Билет №19

1. Муса Җәлилнең лирик героена бәя бирегез, фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез.
2. Фәнис Яруллинның “Җилкәннәр җилдә сынала” повестенда кеше рухының ныклыгы темасының чагылышы.

## Билет №20

1. Татар халык авыз иҗатының төп жанрларынан берсе буларак бәетләр, аларга хас сыйфатлар.
2. Һади Такташның “Мокамай” әсәрендә анализ аша автор идеясен табыгыз.

## Билет №21

1. Татар халык авыз иҗатының төп жанрларынан әкиятләр, риваять, легендалар, аларга хас сыйфатлар.
2. Миргазиян Юнысның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повестенда сугыш темасының яңача чагылышы.

## Билет №22

1. Гаяз Исхакыйның “Җан Баевич” әсәре мисалында комедия жанрына хас үзенчәлекләр хакында сөйләгез.
2. Мирсәй Әмирнең “Агыйдел” повестенда Гаяз образына характеристика бирегез.

## Билет №23

1. Һ.Такташның бер әсәре мисалында шагыйрь һәм лирик герой төшенчәләрен аңлатыгыз.
2. Хәсән Туфанның “Киек казлар” шигырендә лирик герой кичерешләре, киек казлар образына салынган мәгънә.

## Билет №24

1. Татар драматургиясенең формалашу тарихы һәм аның үсеше.
2. Гаяз Исхакыйның “Җан Баевич” драмасында конфликт үзенчәлеге һәм аның аша автор уздырган идея.

## Билет №25

1. Аяз Гыйләҗев иҗаты, үзенчәлекләре, аның иң яхшы әсәрләреннән буларак “Җомга көн, кич белән” повесте.
2. Илдар Юзеевның “Гашыйклар тавы” әсәрендә Мөнирә һәм Сәет образларына чагыштырма бәя бирегез.

**<u>Төзүчеләр</u>:**
Филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Д.Ф.Заһидуллина,
Филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Н.М.Юсупова